## Август аенда кояш чыгу, кояш бату һәм намаз уку вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Кояш бата Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 3.24 | 4.54 | 13.05 | 18.06 | 20.39 | 22.09 |
| 2 | 3.26 | 4.56 | 13.05 | 18.05 | 20.37 | 22.07 |
| 3 | 3.28 | 4.58 | 13.05 | 18.04 | 20.35 | 22.05 |
| 4 | 3.29 | 4.59 | 13.05 | 18.02 | 20.33 | 22.03 |
| 5 | 3.31 | 5.01 | 13.05 | 18.01 | 20.31 | 22.01 |
| 6 | 3.33 | 5.03 | 13.05 | 18.00 | 20.29 | 21.59 |
| 7 | 3.34 | 5.04 | 13.05 | 17.59 | 20.28 | 21.58 |
| 8 | 3.36 | 5.06 | 13.05 | 17.58 | 20.26 | 21.56 |
| 9 | 3.38 | 5.08 | 13.05 | 17.56 | 20.24 | 21.54 |
| 10 | 3.39 | 5.09 | 13.05 | 17.55 | 20.22 | 21.52 |
| 11 | 3.41 | 5.11 | 13.05 | 17.54 | 20.20 | 21.50 |
| 12 | 3.43 | 5.13 | 13.05 | 17.52 | 20.18 | 21.48 |
| 13 | 3.45 | 5.15 | 13.05 | 17.51 | 20.16 | 21.46 |
| 14 | 3.46 | 5.16 | 13.05 | 17.49 | 20.13 | 21.43 |
| 15 | 3.48 | 5.18 | 13.05 | 17.48 | 20.11 | 21.41 |
| 16 | 3.50 | 5.20 | 13.05 | 17.47 | 20.09 | 21.39 |
| 17 | 3.51 | 5.21 | 13.05 | 17.45 | 20.07 | 21.37 |
| 18 | 3.53 | 5.23 | 13.05 | 17.44 | 20.05 | 21.35 |
| 19 | 3.55 | 5.25 | 13.05 | 17.42 | 20.03 | 21.33 |
| 20 | 3.57 | 5.27 | 13.05 | 17.40 | 20.01 | 21.31 |
| 21 | 3.58 | 5.28 | 13.05 | 17.39 | 19.58 | 21.28 |
| 22 | 4.00 | 5.30 | 13.05 | 17.37 | 19.56 | 21.26 |
| 23 | 4.02 | 5.32 | 13.05 | 17.36 | 19.54 | 21.24 |
| 24 | 4.03 | 5.33 | 13.05 | 17.34 | 19.52 | 21.22 |
| 25 | 4.05 | 5.35 | 13.05 | 17.32 | 19.49 | 21.19 |
| 26 | 4.07 | 5.37 | 13.05 | 17.31 | 19.47 | 21.17 |
| 27 | 4.09 | 5.39 | 13.05 | 17.29 | 19.45 | 21.15 |
| 28 | 4.10 | 5.40 | 13.05 | 17.27 | 19.43 | 21.13 |
| 29 | 4.12 | 5.42 | 13.05 | 17.25 | 19.40 | 21.10 |
| 30 | 4.14 | 5.44 | 13.05 | 17.24 | 19.38 | 21.08 |
| 31 | 4.16 | 5.46 | 13.05 | 17.22 | 19.36 | 21.06 |

*Намаз вакытлары турында мәгълүматларны Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте хезмәткәрләре үзерләде, мөфти Вагыйз хәзрәт ЯРУЛЛИН раслады. Җомга көннәре аерып күрсәтелгән.*


**Учредители: трудовой коллектив редакции газеты «Бердэмлек» и Региональное Духовное управление мусульман Самарской области.**

**Оештыручылар: «Бердәмлек» газетасы редакциясенең хезмәт коллективы һәм Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте.**



بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

# КЫЙБЛА

„БЕРДӘМЛЕК" ГАЗЕТАСЫНЫҢ АЙЛЫК ДИНИ КУШЫМТАСЫ

№ 7
2012 ел
июль

№ 30 (1157), 21 июль 2012 ел


ВӘГАЗЬ

# Иманыбызны ныгыткан, күңелебезне сафландырган ай

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

Мөбарәк булсын Рамазан айларыбыз. Аллаһы Сүбхәнәһү вә Тәгалә илләребезгә, көннәребезгә хәерле иминлекләр, тынычлыклар, авыруларга хәерле шифалар, тәүфыйксызлыкта йөргәннәргә тәүфыйк-һидәятләр насыйп әйләсен.

Рамазан ае - рәхмәт, мәгъфирәт, сабырлык ае, ризыкның кадерен, мескен-ятимнәрнең хәлен белә торган ай. Сабыр итә торган, изгелекне күп эшли торган аебыз килеп җитте. Мөбарәк булсын җөмләбезгә дә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм Рамазан ае хакында Шәгъбан аеның ахыргы көннәрендә менә шушы сүзләрне әйтте: *«Безгә, мөхтәрәм мөселман кардәшләрем, Рамазан ае үзенең күләгәсен салды. Ул айда бер кичә бар. Бу - Кадер кичәсе, ул мең кичәдән артык. Кем дә кем шул кичәдә Аллаһы Тәгаләгә зикерләр әйтеп, төн уртасында торып, тәһәҗҗүд намазларын укып, сәхәр вакытында Аллаһыдан дога кылып сораса, ул бәндәнең догалары кабул ителер. Чөнки шушы төндә рәхмәт фәрештәләре таң беленгәнче бәндәләрнең догаларын кабул итеп, Аллаһыга ирештереп торалар».*

Шушы мөбарәк айларыбыз килеп җитте. Аллаһы Сүбхәнәһү вә Тәгалә Коръән-Кәримендә әйтте: «*...фәмән шәһидә миң-күмүш-шәһра фәльйәсумһү...» «И, иман китергән бәндәләрем, сәламәт, гайрәтле, көчле, куәтле, акыллы хәлегездә Рамазан аена ирешсәгез, ураза тотыгыз»*, – диде. Бер елда унике ай, шуның берсе – Рамазан ае. Бу айда Аллаһы Тәгалә безнең иманнарыбызны, ихласыбызны һәм Аңа булган мәхәббәтебезне ризык һәм башка нәрсәләрдән тыю белән сыный торган була. Кайбер бәндәләр хәрәмнән дә тыела алмаган вакытта, без хәләл булган нәрсәләрдән дә тыелып, бер Аллаһының ризалыгын өмет итеп, ураза тотабыз, ач торабыз. Аллаһы Тәгалә зур ачлыклардан сакласын. Әби-бабаларыбыз җәйнең иң эссе, озын көннәрендә дә уразаларын калдырмаганнар. Ачтан үләбез дип курыкмаганнар, тәртипле, тәүфыйклы, динле булганнар һәм безгә дә үз диннәрен ирештерә алганнар. Әгәр без шундый муллыкта яшәп тә, ураза тотмасак, Аллаһы каршында ничек җавап бирербез?!

Пәйгамбәребез (г.с.) әйтте: *«Әгәр бер кеше алдында Рамазан ае үтеп китеп тә, ул кешенең гөнаһлары ярлыканмаса, әти-әнисе булып та, аның догасын алмаса, ул бәндәгә үкенеч булсын»*, – диде. Ләкин беребезнең дә үкенечтә каласы килми. Елдан-ел, көннән-көн ураза тотучы кешеләрнең саны артып бара, мәдрәсәләрдәге шәкертләр күбәйгәннән-күбәя, мәхәлләләрнең саны һәм андагы намазга йөрүче кардәшләребезнең саны арта. Болар бик зур бәрәкәт, җөмһүриятебезгә, милләтебезгә бәрәкәт, иншә Аллаһ, шулай дәвам итсә, без бик зур дәрәҗәләргә ирешербез, инша Аллаһ. Аллаһы Тәгаләдән шуны өмет итеп калабыз.

Пәйгамбәребез (с.г.в. с.) үзенең мөбарәк хәдисендә әйтте: *«Рамазан аенда ураза тотучы бәндәләргә күп сөенечләр бар».* Ике зур сөенечкә ия булабыз. Беренчесе: көндез ураза тотканнан соң, ифтар вакытында ризыкка ирешү сөенече. «Әлхәмдүлилләһ, шушы көннең уразасын тотып, ифтарга ирештем. И, Раббым, тоткан уразаларымны кабул итсәң иде, бәндәчелек белән кылган гөнаһ-хаталарымны тоткан уразаларым бәрәкәтендә ярлыкасаң иде», – дип ризыкны «бисмиллә» әйтеп кабуыгыз - бу бик зур сөенеч. *«Моннан да артыграк сөенеч,* – ди Пәйгамбәребез (с.г.в.с.), – *бу кыямәт көнендә Аллаһы хозурына барган вакытта тоткан уразаларыгыз бәрәкәтендә җәннәтләргә ирешүегез».*

Аллаһы Тәгалә безнең иманыбызны ачлык белән сыный. Бу - бик зур сынау, чөнки беркем күрмәсә дә, янында беркем булмаса да, ризык бар. Ләкин Аллаһының ризалыгын өмет итеп, ризыктан, хәләл икмәкләрдән тыелабыз. Әлхәмдүлилләһ, сынатмыйбыз, уразаларыбызны тотабыз. Намазга басып өлгермәгән кешеләр дә ураза тоталар. Алар: «Безнең тоткан уразаларыбыз кабул булырмы икән?» – дип кайгыралар.